ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 73 “29” 01 2021 ел

«Җир эшләрен җитештерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 21 августындагы 426 номерлы карары белән расланган Спас муниципаль районы территориясен вакытлыча төзекләндерүне тәэмин итүче җир эшләрен җитештерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең уртак коллегиясе беркетмәсен үтәү йөзеннән, 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәлеше йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елның 4 гыйнварындагы ПР-3 номерлы бурычлары буенча, ТР Спас муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Җир эшләрен җитештерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2009 елның 21 августындагы 426 номерлы карары белән расланган Спас муниципаль районы территориясен вакытлыча төзекләндерүне тәэмин итүче җир эшләрен җитештерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Кагыйдәләрнең 2 пунктын түбәндәге эчтәлекле 2.2.9 пунктчасы өстәргә: «2.2.9. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә, моңа авария хәлендәге хәлләргә бәйле очраклар керми».

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин